

Үзенен очаяклы дустына мәхәббәтен Абу Билял улы Батеряков тормышы аркылы 76 ел үткәрә һәм бүген дә мотоцикл дустыннан аерылмый.

Ин беренче мотоциклын – ИМ-72 Абу Билял улы Батеряков 1968 елда сатып ала. Шул вакыт Ләмберәнен МСОсында эшләгән чагы. Яна гына, баш-күзле булып, ойләнгән вакыты. Тормыш иптәше Голсен Хәмзә кызы иренен мотоцикл алуына каршы килми, чонки ул күнел ачу очен түгел, ә эшкә йорергә һәм шәһәргә кирәк-яракка чыгар очен ала. Абу Билял улы техниканы ярата, белә һәм ремонтларга да кулы ятып тора; ватык техникада йорми ул, вакытында үзе тозәтә. Житмәсә, бертуганына да техникасынын кайсы жире ватылганын анларга ярдәм итә. Сонрак, 1982нче елда, Батеряковлар модага кергән һәм яна маркалардан саналган «Урал» мотоциклын сатып алалар. Бу техника күләме һәм момкинчелекләре ягыннан алдагысыннан кочле. Менә шул очаяклы дустында язма героебыз бүген дә жилдертә генә – кая барып, кайдан гына килми житмеш алты яшьлек Абу Билял улы матаенда! Һәм бүген дә үзе үк шул «кентекләгән» техникасын тозәтә дә.

Оста куллы А.Б.Батеряковнын эшлә-гән эшләре байтак; хужалыкта хезмәт житәрлек бит. Үз куллап мунчасын баштан алып азагына кадәр тозн, бурасын күтәрергә генә булышалар. Бакчасында кызыксынып эшли, торле агачлар үстерә, яшелчәләр житештерә. Кош-кортсыз да тора алмый инде авыл кешесе: барысын да булдыра. Остәвенә умарталыгы да бар. Үзе генә түгел, улы Азатка да умарталар белән дуслашырга ярдәм итә. Алар бүген икәүләшеп умарта кортларын тәрбиялиләр. Бер караганда, кеше лаеклы ялда - ял ит тә бетте. Юк, тынгы белмәгән жан эшсез тора алмый, ул шундый булып туган, ана шундый тәрбия биргән әти-әнисе. Абу Билял улы утырып эшсез торырга яратмый. Кендек каны белән кергән ана шул осталык. Абу Билял улы Батеряков 1941нче елда Ләмберә районы Мельцапино авылынын күпбалалы (алты бала) гаиләсендә туа. Әтисе, Билял Фәхретдин улы, оч сугыш кырын кичкән кеше: финнар белән корәшкән, немецлар һәм японнар белән! Шуна гаиләнен хужалык эшләре хатыны һәм балалары жилкәсендә була. Авыл кешесендә, бигрәк күпбалалы гаиләдә, сыер асрамый булмый инде – сыер асрыйлар. Алар тагы сарыклар, кош-корт та асраганнар. Абу Билял улынын әнисе колхозда эшләгән вакытта, шул замана балалары

тосле, ул иртә олыгаеп, яшьли нужа тарта башлый. Батеряковлар балалары кадерле әниләренә бар эштә ярдәмче булалар; мал-туар артыннан да, йорт-жир артыннан да караштырып торалар. Эшне дә жиренә житкереп башкарырга шул вакытта ук ойрәнәләр. Әмма белем алу турында да онытмыйлар. Мәктәптә укыткан беренче укытучысы Гелнур апа Хансвярованы бvген дә жылы искә ала Абу Билялович: «Гелнур апа Мельцапино балаларын дvртъеллык мәктәптә хәреф танырга, укый-язарга, санарга ойрәтеп кенә калмады, ул балалар белән дvсларча могаләмәдә иде».
Бу гаиләнен бәхетенә әтиләре фронттан исән-сау кайта. Һәм 1953нче елны Батеряковлар гаиләсе Ләмберәгә яшәргә кvченеп киләләр. Билял Фәхретдин улы РАЙПОга председатель иттереп эшкә урнаштырылган була. Абу Билял улы мәктәпне Ләмберәдә тәмамлый. Аннары МСОга эшкә урнаша. Тырышлыгын һәм белемен кvреп складка заведующий (модир) булып билгеләнә. Бу елларда колхозара тезv оешмасы зурлардан саналган, чонки тезv эшләрен районара хужалыкларында алып барганнар. Бу оешмада машиналар гына утызлап булган, унлап трактор һәм башка тор техника. Шуларнын барысы да склад модиренә кагылышлы.
Заманалар vзгәрә һәм без дә анын белән алга атлыйбыз. 1963нче елда, районнар берләшкән чакта, Абу Билял улы Саранск башкалабыз заводына хезмәткә урнаша. Люминесцент лампаларын жайга салу эше белән шогыльләнә. Менә шунда, заводта, vзенен киләчәк тормыш иптәше белән таныша да язма героебыз. Алар, бик тату гаилә буларак, илле елдан артык бергә гомер итәләр, балалар тәрбияләп vстерәләр, оныкларга шатланып, ярдәм итеп яшиләр. Еллар артыннан еллар vткәнен сизми дә каласын. Сонрак, якын булып олгергән Ләмберәгә эшкә кайта А.Б.Батеряковыбыз һәм һаман булдырган эше – склад модире булып хезмәт юлын дәвам итә. Хормәтле хезмәткәр буларак лаеклы ялга чыга ул. Тагы берничә ел эшләп алгач, тормышын хужалык эшләренә багышлый.

Наилә Насырова